**Татарстан Республикасы**
**Тукай муниципаль районы**
**“Әҗмәкәй авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлек Советы**

# К А Р А Р

«24» сентябрь 2018 ел №39/6

« Әҗмәкәй авыл җирлегендә Җирле референдум билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20,35 статьялары, «җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 **Әҗмәкәй авыл** җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 17 сентябрендәге 20 номерлы карары белән, **Әҗмәкәй авыл** авыл җирлеге Советының 2018 елның 26 сентябрендәге 19/1 номерлы карары, **Әҗмәкәй авыл** җирлеге Уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы,

**КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Әҗмәкәй авыл җирлегендә 2018 елның 18 ноябрендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрүне билгеләргә.

2.”Әҗмәкәй авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Советы Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Әҗмәкәй авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында һәм референдум сорауларын түбәндәгечә тәкъдим итте:

"Сез 2019 елда Әҗмәкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз картайган гражданнар, күп балалы гаилә һәм студентлар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә һәм әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә ризамы һәм әлеге сумма түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәкбез:

- Әҗмәкәй авыл җирлегендә юлларны ремонтлау
- Яңа поселогында балалар мәйданчыгын төзекләндерү
- Зиратны койма белән әйләндереп алу Әҗмәкәй авылында
- Әҗмәкәй авыл җирлегендәге авылларында урам утларын урнаштыру;

3. Референдум әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссиясенә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе) ;
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Биклән авыл җирлеге бюджеты хисабына тормышка ашырга.
5. Әлеге карарны «Якты юл» («Якты юл») газетасында бастырырга.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.
7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе М.Г.Фазылҗанов